ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.03.2020 07

с. Русское Макулово

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен санитар-экологик чистарту буенча икеайлык үткәрү турында

Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм халыкның экологик иминлегенә җавап бирерлек хәлгә китерү өчен эшләр башкаруны оештыру өчен, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 4 мартындагы 157 номерлы карарын үтәү йөзеннән,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Макыл авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту икеайлыгын игълан итәргә (алга таба – икеайлык).
2. Макыл авыл җирлеген төзекләндерү комитеты составын 2020 елга расларга (1кушымта).
3. 2020 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Макыл авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү буенча чаралар планын расларга (2 кушымта).
4. Макыл авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләренә, милек формасына карамастан, якын-тирә территорияләрне санитар чистарту эшен оештырырга, икеайлык кысаларында оештырылган полигонга һәм чүплеккә каты көнкүреш калдыклары чыгару өчен йөк транспорты бүлеп бирергә тәкъдим итәргә. Урыннарда агачлар һәм куаклар утырту, биналарның фасадларын, балалар мәйданчыкларын ремонтлау эшен оештырырга.
5. Нинди хокукка карамастан, авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек булган гражданнарга йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш үткәрергә тәкъдим итәргә.
6. Бу карарны Макыл авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам

Макыл авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р. Цветкова

Макыл авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесенең
2020 елның 23 мартындагы
7 номерлы карарына
1 кушымта

Макыл авыл җирлеген төзекләндерү
комитеты составы

1. Цветкова Лилия Рашидовна
Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе

2. Гарифуллин Камиль Исмагилович
«Восток ашлык продуктлары» АҖ механизаторы

3. Родионов Игорь Владимирович
3 номерлы Рус-Макыл сайлау округы депутаты

4. Хакимов Рузалит Талгатович
10 номерлы Клянчино сайлау округы депутаты

5. Панасик Николай Владимирович
МБОУ «Макыл урта мәктәбе» директоры

6. Ахтямова Вероника Валерьевна
9 номерлы Сеитово сайлау округы депутаты

7. Гайнутдинов Рустам Киямутдинович
Агрофирма «Югары Ослан» ҖЧҖ генераль директоры

8. Хасанова Дания Наилевна
Рус Макылы авылында яшәүче пенсионер

Макыл авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесенең
2020 елның 23 мартындагы
7 номерлы карарына
2 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен
чистарту буенча санитар чаралар планы

Т.б. №	Чара исеме	Үткәрү вакыты	Җаваплылар
1	Авыл җирлеге территориясендә урнашкан чүплекләрне юк итү буенча эшләрне оештыру һәм үткәрү	01.04.2020 01.05.2020	Башкарма комитет җитәкчесе, учреждение, оешма, предприятие җитәкчеләре.
2	Авыл җирлеге территориясендә торак пунктлар эчендә баганалар агарту	25.04.2020 30.04.2020.	Башкарма комитет җитәкчесе, учреждение, оешма, предприятие җитәкчеләре.
3	Авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждение, предприятие, оешмаларның биналарының фасадларын ремонтлау	15.04.2020 30.04.2020	Учреждение, оешма, предприятие җитәкчеләре.
4	Биналарының фасадларын ремонтлау	15.04.2020 05.05.2020	Милекчеләр, авыл җирлеге территориясендә торак биналарны яллаучылар
5	Авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү (коймаларны ремонтлау, коймаларны буяу, чүп чыгару)	01.05.2020 31.05.2020	Башкарма комитет җитәкчесе, учреждение, оешма, предприятие җитәкчеләре.
6	Авыл җирлеге һәм территорияләрдә чишмәләрне төзекләндерү	01.05.2020 31.05.2020	Башкарма комитет җитәкчесе, учреждение, оешма, предприятие җитәкчеләре.
7	Авыл җирлеге торак пунктларында яшел үсентеләр утырту.	24.04.2020 15.05.2020	Башкарма комитет җитәкчесе, учреждение, оешма, предприятие җитәкчеләре.
8	Авыл җирлеге эчендәге юлларны ремонтлау (грейдирлау, вак таш җәю)	01.05.2020 31.05.2020	Башкарма комитет җитәкчесе, учреждение, оешма, предприятие җитәкчеләре.
9	Клумбалар ясау һәм ремонтлау, чәчәкләр утырту	30.05.2020 кадәр	Башкарма комитет җитәкчесе, учреждение, оешма, предприятие җитәкчеләре.
10	Урамнарны грейдирлау, юл кырыйларын һәм юл буйларын чабу	20.05.2020 кадәр	Башкарма комитет җитәкчесе, учреждение

11	Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар һәйкәленә косметик ремонт	09.05.2020 кадәр	Башкарма комитет җитәкчесе, учреждение, оешма, предприятие җитәкчеләре.